# ӘЛДЕРМЕШКӘ КАЙТАМ ӘЛЕ

*У.РАШИТОВ көе*
*Т.НИЗАМИ сүзләре*

Сая елгалары ага
Текә ярларга тулып.
Агар идем шул якларга
Чишмә моңнары булып.

*КУШЫМТА:*
Кайтам әле Әлдермешкә,
Чишмәгә төшәм әле.
«Һаман сине сөям» — диеп,
Серемне чишәм әле.

Су чәчрәтеп уйнап үстек
Сөйдеркә буйларында.
Тере су тамчыларыдай
Калдың син уйларымда.

*КУШЫМТА*

Эчсәң Сөйдеркә суларын
Сизмәссең дә салкынын.
Яшәү көчең, дәртең артыр,
Дөрләр йөрәк ялкының.

*КУШЫМТА*

Әлдермеш якларын бизи
Мәхәббәт үзәннәре.
Ут йөрәкле егетләре,
Тиңдәшсез гүзәлләре.

*КУШЫМТА*